ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Мөҗипова Гөлнара Альберт кызының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составындагы үзгәреш турында.
5. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 144-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 128-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 129-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
8. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 146-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 142-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы

Законына үзгәрешләр кертү хакында» 143-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

12. 2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.

13. 2021 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.

14. «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

15. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1052643-7 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль хезмәткә урнашканда тапшырыла торган белешмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

16. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1065287-7 номерлы федераль закон проекты хакында (чит дәүләт гражданлыгы булуга йә чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукына ия булуга бәйле рәвештә дәүләт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, башка вазыйфаларны биләүгә чикләүләр өлешендә).

17. «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 1058461-7 номерлы федераль закон проекты хакында (этил спирты җитештерү өчен төп технологик җиһазга карата җитештерү куәтеннән минималь файдалану нормаларын куллану тәртибен камилләштерү өлешендә).

18. «Россия Федерациясе Торак кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 1045025-7 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

19. «Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясына үзгәреш кертү турында» 1057393-7 номерлы федераль закон проекты хакында (су законнары, балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турындагы законнар нормаларын яр буе саклау полосасының киңлеген билгеләү өлешендә синхронлаштыру максатларында).

20. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия

Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Пермь крае Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1050733-7 номерлы федераль закон проекты турында (Халыкара хәрби трибуналның хөкеме белән билгеләнгән фактларны инкарь итүче мәгълүматны тараткан, шулай ук Икенче бөтендөнья сугышы елларындагы СССР эшчәнлеге хакында күрәләтә ялган мәгълүматны гавами рәвештә тараткан өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1060586-7 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозу турында эш буенча производствоны туктату нигезләре исемлеген төгәлләштерү хакында).

23. 2020 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

24. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
урынбасары — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2020 елның 16 декабре
№ 741-VI ДС